Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл җирлеге Советы Карары

«30» октябрь 2020 ел № 7

**11.11.2009 ел № 109 Күңгәр авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә Күңгәр авыл җирлеге Советы карар итте:

1 .Әтнә муниципальрайонының «Күңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Күңгәр авыл җирлеге Советының 11.11.2019 ел, № 109 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 10 статьяның 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга

**1.2.**34 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.Җирлек советы keремнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм җирлек Советының бюджет турындагы карар проектын җирлек Советына керткәннән соң кабул ителгән карарларының нигезләмәләре Чираттагы финанс елында, агымдагы финанс елына һәм план чорына җирлек бюджетына үзгәрешләр кертәндә, агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә исәпкә алына.»

**1.3.**27 статьяның 16 пунктындагы 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга

**1.4**.15 статьяның 15 абзацын үз көчен югалткан дип танырга

**1.5**.45 статьядагы 3 пунктта "түләү документлары" сүзләрен "казначылык түләүләрен башкару турында күрсәтмәләр (алга таба - күрсәтмә)" сүзләренә алмаштырырга, "түләү документлары" сүзләрен "күрсәтмә" сүзләренә алмаштырырга."

2.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында ,Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча ) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында : (pravo.tatarstan.ru ) веб –адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Күңгәр авыл җирлеге башлыгы И.И.Салахов